СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
10 июля 2015 года

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№548

Зеленодольск муниципаль район Советының 2012 елның 31 августындагы 185 номерлы «Татарстан Республикасы « Зеленодольск муниципаль районы » муниципальь берәмлегендә жирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрлә-нең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре,мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Зеленодольск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2013 елның 13 июнендәге 282 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр кертү турында

2014 елның 22 декабрендәге 431 номерлы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 23 мартындагы УП 308 номерлы «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» Указын исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль район Советы карары белән расланган 2012 елның 31 августындагы 185 номерлы «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Зеленодольск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2013 елның 13 июнендәге 282 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасының “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Зеленодольск муниципаль районы Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып

чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2 пунктны түбәндәге эчтәлекле «г» пунктчасы белән өстәргә:

«г) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) муниципаль хезмәткәрнең һәм аның хатынының (иренең) гомуми кереме хисап чорына кадәрге соңгы өч ел эчендә артып китсә, җир участогы, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (катнашу өлешләрен, пайларны) сатып алу буенча алыш-бирешләр ясалган (алыш-биреш ясалган) акча алу чыганаклары турында белешмәләр».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**